**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

**утыз икенче утырыш**

**1 ноябрь 2024 ел** **№141** **Теләче ав.**

**Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 ноябрендәге 113 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 12 июлендәге 05-11/4815 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 ноябрендәге 113 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында», (26.07.2024 №133 карары редакциясендә), карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2 пунктчасында “, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата” сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән тулыландырырга

"2.1) салым салу объектларына карата 2,5 процент, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;";

- 2 пунктны түбәндәге редакциядәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) 2025-2027 еллар чорына 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйдандагы сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләргә (комплексларга) карата һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарга карата 1,2 процент.»;

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы И.З. Ярмиев